РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.03.2023 Олы Кайбыч ав. № 18

Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасының Кайбыч звеносы идарә органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек режимын кертү турында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә хосусый йорт биләмәләрен су басу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 08 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасының (алга таба ТП РСЧС) идарә органнары һәм Кайбыч звеносы көчләре өчен 2023 елның 17 мартында 19.00 сәгатьтән алып Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясе чикләрендә муниципаль реакция дәрәҗәсен билгеләүне махсус күрсәтмәгә кадәр югары әзерлек режимы кертергә.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләренә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) югары әзерлек режимында эшләгәндә Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Кайбыч звеносының идарә органнары эшчәнлеген координацияләү;

б) оператив хәл начарайганда (гадәттән тыш хәлләр килеп туганда) Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Кайбыч звеносы көчләренең эшкә керешергә әзер булуы;

в) федераль башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның әлеге боерыкны гамәлгә ашырганда гамәлләренең килештерелүе.

3. Әлеге күрсәтмәне гамәлгә ашыруны тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә (килешү буенча).

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адресы http://kaybici.tatarstan.ru буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo. tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

А.И. Рәхмәтуллин